| ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО ТАРИФАМ | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ТАРИФЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ |
|---|---|---|

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

03.11.2016 Казан ш. № 7-16/т

“Татфлот” суднолар йөрү компаниясе” ачык акционерлык җәмгыяте тарафыннан “Тәтеш шәһәре” муниципаль берәмлеге территориясендә урнашкан причалны биреп тору буенча хезмәт күрсәтүгә максималь дәрәҗәдә чик тарифны билгеләү турында

“Табигый монополияләр турында” 17 август, 1995 ел, № 147-ФЗ Федераль законга, “Транспорт терминалларында, портларда, аэропортларда табигый монополияләр субъектлары хезмәтләре күрсәтүгә һәм эчке су юллары инфраструктурасыннан файдалану хезмәтләре курсәтүгә бәяләрне (тарифлар, җыемнар) дәүләти җайга салу һәм контрольдә тоту турында” 23 апрель, 2008 ел, № 293 һәм “Табигый монополияләр субъектлары эшчәнлеген дәүләти җайга салуны һәм контрольлекне хәл итүдә тарифларны дәүләти җайга салу өлкәсендә Россия Федерациясе субъектлары башкарма хакимияте органнарының катнашуы турында” 10 декабрь, 2008 ел, № 950 Россия Федерациясе Хөкүмәте карарларына, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 15 июнь, 2010 ел, № 468 карары белән расланган Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты турында нигезләмәгә туры китереп, Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты КАРАР бирә:

1. “Татфлот” суднолар йөрү компаниясе” ачык акционерлык җәмгыяте тарафыннан “Тәтеш шәһәре” муниципаль берәмлеге территориясендә урнашкан причалны биреп тору буенча хезмәт күрсәтүгә максималь дәрәҗәдә чик тарифны әлеге карар кушымтасы нигезендә билгеләргә.

2. “Татфлот” суднолар йөрү компаниясе” ААҖ тарафыннан Тәтеш шәһәре территориясендә урнашкан причалларны биреп тору буенча хезмәт күрсәтүгә максималь дәрәҗәдә чик тарифны билгеләү турында” Татарстан Республикасы тарифлар буенча Дәүләт комитетының 2012 елның 18 апрелендәге 7-8/т санлы карарын үз көчен югалткан дип санарга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан соң 10 көн узгач үз көченә керә.

Рәисе М.Р.Зарипов

Татарстан Республикасының
тарифлар буенча дәүләт комитетының
03.11.2016 № 7-16/т
карарына кушымта

“Татфлот” суднолар йөрү компаниясе” ачык акционерлык җәмгыяте тарафыннан “Тәтеш шәһәре” муниципаль берәмлеге территориясендә урнашкан причалны биреп тору буенча хезмәт күрсәтүгә максималь дәрәҗәдә чик тариф

| № п/п | Хезмәт күрсәтү төре | Үлчәү берәмлеге | Тариф |
|---|---|---|---|
| 1. | Йөк операцияләрен башкармыйча гына судно куеп тору өчен причал бирү | Судноның габарит озынлыгының 1 метры өчен сум./сәг. | 20 |

Искәрмәләр:

1. “Татфлот” суднолар йөрү компаниясе” ачык акционерлык җәмгыяте (алга таба - Җәмгыять) тарафыннан “Тәтеш шәһәре” муниципаль берәмлеге территориясендә урнашкан причалны биреп тору буенча хезмәт күрсәтүгә максималь дәрәҗәдә чик тарифны куллану Россия Федерациясе законы нигезендә хәл ителә.
2. Җәмгыять клиентлар белән килешүләр төзегәндә максималь дәрәҗәдә чик тарифны яки аннан кимрәк тарифны куллануга хокуклы.
3. Максималь дәрәҗәдә чик тариф өстәмә кыйммәткә салымны исәпкә алмыйча күрсәтелә.
4. Казан шәһәре территорясендә урнашкан причалны йөк операцияләрен башкармыйча гына судно куеп тору буенча хезмәт күрсәтү бәясе әлеге карарның кушымтасы нигезедә причалда тору вакытын судноның габарит озынлыга тапкрылап билгеләнә.

Татарстан Республикасы тарифлар буенча
Дәүләт комитеты, Тарифлар буенча карарларны
кабул итү, оештыру һәм җайга салу бүлеге